ПӘНҖЕШӘМБЕ
15 ФЕВРАЛЬ
1940 ел
№ 37 (5837)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

МОСКВА, КРЕМЛЬ

СТАЛИН һәм МОЛОТОВ ИПТӘШЛӘРГӘ

Иптәш Сталин исемендәге Зур Ферганә каналын Канибадам шәһәреннән Ленинабад шәһәренә кадәр житкерү турында ССР Союзы Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының 1939 нчы ел 21 нче октябрь карарының үтәлгәнлеген хәбәр итәбез. Колхозчылар, административ-инженер-техник персонал, политработниклар, җәмагат туклануы һәм сәүдә, сәнгат, медицина һәм транспорт работниклары, иптәш Сталин исеме белән рухланып, большевиклар партиясе җитәкчелегендә, 15 көн эчендә кышкы шартларда җир эшләрен тәмам иттеләр һәм 79 километр озынлыгында канал төзеделәр.

Шулай итеп, Таҗикстанның 50 мең хезмәт иясе рекордлы кыска срок эчендә иптәш Сталин исемендәге Зур Ферганә каналының беренче һәм икенче чираты буенча 126 километр төзеделәр һәм шуның белән Таҗикстанның төньяктагы күп кенә районнарында су азлыкка чик куйдылар һәм колхозларда таза тормышның тагын да чәчәк атуын тәэмин иттеләр.

Таҗикстан КП(б) ҮК секретаре ПРОТОПОПОВ.
Таҗикстан ССР Совнаркомы председателе КУРБАНОВ.
Сталинабад, 13 февраль. (ТАСС).

БАШЛАНГЫЧ ПАРТОЕШМАЛАРДА ОТЧЕТ-САЙЛАУ ҖЫЕЛЫШЛАРЫ

Партиянең башлангыч оешмаларында бүген отчет-сайлау җыелышлары башлана. ВКП(б) уставы нигезендә үткәрелә торган бу отчет-сайлаулар гаять зур политик әһәмияткә ия булып торалар. Партия оешмалары отчет-сайлау җыелышларын үрнәк булырлык итеп оештырырга, җыелышларга һәрбер коммунистның актив катнашуын тәэмин итәргә тиешләр.

Бик ачык ки, безнең партиябезнең организацион төзелешендә җитәкче принцип булып демократик централизм тора. Бу исә партиянең түбәннән алып югарыга кадәр барлык җитәкче органнарының сайланулы булуын, партия органнарының үз оешмалары алдында периодик рәвештә отчет бирүләрен таләп итә. Партия кадрларын түбәннән тикшерү—менә шушы отчетлардан гыйбарәт булачак. Чөнки **„партиялеләр массасы үзләренең җитәкчеләрен активларда, конференцияләрдә, съездларда, аларның отчетларын тыңлау юлы белән, җитешсезлекләрне тәнкыйтләү юлы белән, ниһаять, теге яисә бу җитәкче иптәшләрне җитәкче органнарга сайлау яисә сайламау юлы белән тикшерәләр“ (Сталин).**

Партия органнарында булган соңгы сайлаулардан бирле ике елга якын вакыт үтте. Бу чор эчендә, маглүм ки, партиябез тормышында гаять зур һәм гаять әһәмиятле вакыйгалар булды. Партия оешмалары ВКП(б) ның тарихи XVIII нче съезды карарлары белән һәм бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин күрсәтмәләре белән коралланып, гаять зур эшләр башкардылар. Партия оешмаларының хуҗалык мәсьәләләре белән шөгыльләнүләре шактый көчәйде, партия-политик эшне һәм агитация-масса эшләрен хуҗалык бурычларына дөрес бәйләп алып бару нәтиҗәсендә, промышленностьта һәм авыл хуҗалыгында хезмәт җитештерүчәнлеге яна баскычка күтәрелде, партиянең эчке эшләре күп тапкырлар яхшырды һәм ул бер туктаусыз яхшыра бара.

ВКП(б) ның башлангыч оешмалары җитәкчеләре үзләренең отчетларында партия оешмасының уңышларын һәм җитешсез якларын тулы рәвештә чагылдырырга тиешләр. Партия сафларын үстерү, яңа, яшь кадрларны җитәкче эшләргә күтәрү, үтәлүне тикшерү, партия пропагандасы, комсомол һәм профсоюз оешмаларына җитәкчелек мәсьәләләренә отчет докладында киң урын бирелергә тиеш. Партия оешмаларының эшләрендә яшәп килә торган җитешсезлекләрне большевистик кыюлык белән ачып салырга кирәк. Отчет-сайлау җыелышларында большевистик тәнкыйть һәм үзеңне тәнкыйтьләү тулы көченә яңгырарга тиеш. Кемнең кем булуына карамастан, кимчелекләрне һәм аларны тудыручы кешеләрне каты тәнкыйть уты астына алырга! Отчет бирүчедән һәм отчет буенча сөйләүчеләрдән әнә шул таләп ителә.

Отчет-сайлауларда партия оешмаларының төп бурычларыннан берсе һәм иң әһәмиятлесе—партиянең җитәкче органнарына ныклап тикшерелгән кешеләрне, Ленин—Сталин эшенә, коммунизм эшенә ахрынача бирелгәнлекләрен практик эштә күрсәткән талантлы һәм сәләтле кешеләрне сайлауны тәэмин итү. Партиянең җитәкче органына кандидатуралар күрсәткәндә һәм сайлаганда һәрбер коммунист кадрлар сайлап алуның Ленинчел — Сталинчыл принципыннан чыгып эш итәргә, һәрбер кандидатурага зур җиддилек, саклык белән якын килергә тиеш.

Партиянең җитәкче органнарына үткән сайлаулар вактында кайбер урыннарда шушындый зур җитешсезлекләр булды: коммунистлар теге яисә бу иптәшне мактый-мактый партоешманың җитәкчесе итеп сайладылар. Ә беркадәр вакыт үтү белән „булдыксызлык күрсәтү, эшне таркатуы өчен“ дип, ВКП(б) райкомы партоешма җитәкчесен эшеннән алды. Моңа мисаль итеп Казан пристане партоешмасында һәм шорный фабрика янындагы партоешмада булган хәлне күрсәтеп үтү дә җитә. ВКП(б) ның Киров райкомы бу иптәшләрне эшләреннән алырга һәм алар урнына башка кешеләр сайлау мәсьәләсен куярга мәҗбүр булды. Димәк, кадрлар сайлап алганда анкеталар буенча гына эш итмәскә, матур сүзләргә, тышкы ялтырауларга, вагдәләргә карап кына эш итмәскә, бәлки чынбарлыктан чыгып, кешенең нәрсәгә сәләтле булуыннан, аның практик эшеннән, алда торган бурычларны үтәрлекме, түгелме икәнлегеннән чыгып эш итәргә кирәк.

Отчет-сайлауларда партия оешмаларының төп бурычларыннан икенчесе—коммунистларга ВКП(б) уставы тарафыннан бирелгән хокукларның тулы үтәлүен тәэмин итү, партия эчендәге демократияне төгәл үтәү. Партия эчендәге демократия турында ВКП(б) уставында болай диелә:

„Партия органнарын сайлаганда исемлек белән тавышка кую тыела. Тавышка кую аерым кандидатуралар буенча үткәрелергә тиеш, шуның белән бергә, партия членнарының барсына да кандидатларга отвод бирү һәм аларны тәнкыйть итү буенча чикләнмәгән хокук тәэмин ителә. Сайлаулар кандидатларны ябык (яшрен) рәвештә тавышка кую юлы белән үткәрелә“. Партия оешмалары сайлаулар вактында менә шушы таләпләрдән чыгып эш итәргә тиешләр.

Партиялеләр массасы алдында отчет бирү һәм партия органнарын сайлаулар гаять җаваплы эш. Партия оешмалары, барлык коммунистлар бу җаваплылыкны аңлыйлар һәм һич шик юк ки, алар—ВКП(б) членнары һәм кандидатлары — партия органнарын сайлауларны идея ягыннан югары дәрәҗәдә үткәрү өчен барлык чараларны күрерләр, партоешмаларның җитәкчеләре итеп иң алдынгы кешеләрне, Ленин—Сталин эшенә ахрынача бирелгән, массаларны яңа җиңүләргә оештырырга сәләтле булган талантлы большевикларны сайларлар. Бу исә партия-политик эшнең, агитация-пропаганда эшенең яңа күтәрелешен тудырыр, коммунизм өчен көрәш фронтында яңа җиңүләрне тәэмин итәр.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

13 нче февральдә фронтта разведчикларның эзләнүләре булды һәм күп кенә районнарда пехота частьләренең һәм артиллериянең җанлы хәрәкәтләре дәвам итте.

Карелия бугазында безнең гаскәрләрнең уңышлы хәрәкәтләре киңәя бара. Зур көчләр белән контратакага күчәргә маташкан дошман зур югалтулар белән таркатылды. Безнең гаскәрләрнең уңышлы хәрәкәтләре нәтиҗәсендә, дошманның ныгытылган 23 оборона пункты алынды.

Безнең авиация разведка очышлары ясады һәм дошманның гаскәрләренә һәм сугыш объектларына сугыш хәрәкәтләре алып барды.

Чит илләрдә

Германия белән СССР арасында хуҗалык килешүе төзелү турында Германия матбугаты

БЕРЛИН, 13 февраль. (ТАСС). Германия газеталары бүген үзләренең беренче битләрендә Совет—Германия хуҗалык сөйләшүләренең уңышлы тәмам булуы һәм ике бөек держава арасында экономик сотрудниклыкның тирәнәюе турындагы рәсми хәбәрләрне эре хәрефләр белән басып чыгардылар. „Фелькишер беобахтер“, „Берлинер берзен-цейтунг“, „Дейче альгемейне цейтунг“ газеталары үзләренең беренче битләрендә Совет—Германия хуҗалык килешүе турында Германия информация бюросының хәбәрен дә урнаштырдылар. Бу хәбәрдә ике ил арасында экономик элементләрне үстерү өчен килешүнең гаять зур әһәмияте барлыгы күрсәтелә.

Германия белән СССР арасында хуҗалык килешүе төзү турында Литва матбугаты

КАУНАС, 13 февраль. (ТАСС). Бүген Литваның барлык газеталары Германия белән СССР арасында хуҗалык килешүе төзелү турындагы хәбәрне күрнерлек урында иглан итәләр. Совет—Германия килешүе уңае белән „Лиетувос жиниос“ газетасы Германия белән СССР арасында яңа хуҗалык килешүенә кул кую—ике илнең дә зур казанышы дип, яза.

„XX амжиус“ газетасы, Совет—Германия килешүе ике ил арасында товар обороты күләмен шул кадәр үстерүне күздә тота ки, Германия тарафыннан аның бөтен яшәве вактында төзелгән сәүдә договорларының берсендә дә мондый күләмнең күздә тотылганы юк иде, ди.

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

БЕРЛИН, 12 февраль. Германия информация бюросы Форбах районында ике якның да разведка хәрәкәте нәтиҗәсендә бәрелеш булганлыкны хәбәр итә. Германиянең алгы постына дошман пулеметтан аткан. Германия отрядының бер өлеше французларның флангларыннан кереп аларга Морсбахтан ярдәмче көчләр килүгә тоткарлык ясаган. Форбахның үзендә үзәк урамда һәм казармалар янында Германиянең сакчылык отрядының калган өлеше белән дошман арасында каты сугыш булган. Атышу вактында дошманның 8 кешесе үтерелгән һәм берничә кешесе яраланган. Германиянең сакчылык отряды составыннан бер солдат яраланган.

БЕРЛИН, 13 февраль. Германия армиясенең верховный командованиесе „көнбатыш фронтта әһәмиятле бер вакыйга дә булмады“ дип хәбәр итә.

ПАРИЖ, 13 февраль. Кичә кич һәм бүген иртә белән Парижда иглан ителгән рәсми белдерүләрдә „фронтта бер нинди яңалык булмады“ диелә.

БЕРЛИН, 13 февраль. „Кельнише цейтунг“ газетасы, француз солдатлары белән инглиз солдатлары арасындагы мөнасәбәтләр рәсми төстә хәбәр ителгәнчә дусларча булудан күп ерак тора дип хәбәр итә. Газетаның язуына караганда, фронттан кыска сроклы отпускыга кайтучы француз солдатлары инглиз солдатларына караганда француз солдатларының шактый начар шартларда торуларын сөйлиләр. Англия солдатлары фронт линиясеннән ерактагы позицияләргә урнашканнар. Алар типтерен яшиләр, көненә 30 франк алалар, ә французлар бары берничә сантим гына алалар. Бу акча бер пачка папироска да көчкә генә җитә. Франциягә 40 яшендәге инглиз солдатларын җибәрергә уйлану турында Лондоннан булган хәбәрләргә французларның ачуы кабарды, чөнки бу солдатлар сугышта катнашмаячаклар, бәлки вахтенныйлар, надсмотрщиклар һ. б. булып кына хезмәт итәчәкләр. Шул ук вакытта французлар армиясендә 50 яштәге солдатлар да фронтның алгы линияләрендә хезмәт итәләр.

ФРАНЦИЯДӘ КОММУНИСТЛАРГА КАРШЫ РЕПРЕССИЯЛӘР

БЕРЛИН, 12 февраль. (ТАСС). Бөтен Франциядә коммунистларны һәм сугышка каршы чыгучы кешеләрне эзәрлекләү дәвам итә. Сена һәм Уаза департаменты префекты күп кенә коммунистларны концентрация лагерына япты. Кулга алынганнар арасына Сена һәм Уаза департаментының берничә генеральный советнигы бар. Коммунистлар партиясендә торулары өчен Марсель шәһәренең 67 советнигы мандатларыннан мәхрум ителделәр. Лионның хәрби суды „дәүләтнең куркынычсызлыгына каршы юнәлдерелгән“ хәрәкәтләрдә гаепләп бер эшчене 5 елга мәҗбүри эшкә хөкем итте. Шул ук хәрби суд бер почта хезмәткәрен сугышка каршы сөйләгәне өчен 5 елга төрмәгә хөкем итте.

ФРАНЦУЗ СОЦИАЛИСТЛАРЫ АРАСЫНДА КАРШЫЛЫКЛАР

ПАРИЖ, 12 февраль. (ТАСС). Кичә Франция социалистлар партиясенең җирле оешмалары секретарьларының конференциясе булды. Конференция ябык төстә барды. Журналистларның хәбәр итүләренә караганда, конференция партия эчендәге каршылыкларга кагылышлы мәсьәләләрне тикшергән. Күп кенә делегатлар социалистлар партиясен какшата торган „тын гына бара торган каршылыклар“дан зарланганнар.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Гуанси провинциясенең көньяк өлешендә кытай гаскәрләре инициативаны үз кулларында тоталар. Кытай гаскәрләре резервлар китереп, 10 нчы февральдә японнарны Наньниннан төньяктарак Уминнан бәреп чыгарганнар. Икенче көнне каты сугыштан соң кытайлар Наньниннан төньяк-көнчыгыштарак Биньянны һәм Цзютанны японнардан алганнар. Япон гаскәрләре кытай гаскәрләре частьләре тарафыннан эзәрлекләнгән хәлдә тулысынча тәртипсез рәвештә Наньнинга чигенәләр. Кытай чыганакларыннан алынган хәбәрләргә караганда, югарыда күрсәтелгән пунктлар өчен сугышларда японнарның 5 мең чамасы кешесе үтерелгән һәм яраланган. Кытай гаскәрләре Линьбинь шәһәрен чолгап алганнар.

„Даваньбао“ газетасының хәбәр итүенә караганда, японнарның 5 нче дивизиясенең 2 полковнигы Биньян янында җиңелгәннән соң үз-үзләрен үтергәннәр.

ҮЗӘК КЫТАЙДА

Японнар Чжэцзян провинциясендә, Нинбо якынында яр буена десант төшерергә маташуларын дәвам иттерәләр. Ләкин кытайлар оборонасы японнарның барлык маташуларын кире кага. Японнарның 8 нче февральдә Цяньтан елгасының көньяк ярына чыккан кавалерия часте кытай гаскәрләренең засадасына эләккән һәм зур югалтуларга очраган.

Хубэй провинциясенең төньяк өлешендә 9 нчы февральдә японнар Дахуншань районының көнчыгыш өлешендә 4 колонна белән һөҗүм башлаганнар, ләкин кытай гаскәрләренең ныклы каршылыкларына очрап, Суйчжоуга чигенергә мәҗбүр булганнар.

10 нчы февральдә Янцзы елгасыннан баручы япон транспортына кытайлар артиллериядән атканнар.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА

Соңгы атнада Шаньси провинциясендә сугыш ягыннан әһәмиятле бер нинди үзгәреш булмады.

1940 нчы елның 9 нчы февралендә СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. И. Калинин бүләкләнүчеләргә ССР Союзы орденнары һәм медальләре тапшырды. РӘСЕМДӘ (сулдан уңга): „Батырлык өчен“ медале белән бүләкләнгән лейтенант С. Д. Колотиевский һәм „Сугышчан хезмәтләре өчен“ медале белән бүләкләнгән медицина сестрасы К. А. Русанова иптәшләр. Ф. Кислов фотосы (ТАСС фото-клишесе).

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

123 нче укчы дивизияне Ленин ордены белән бүләкләү турында

Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм шул вакытта батырлык һәм кыюлык күрсәткән өчен 123 нче укчы дивизияне Ленин ордены белән бүләкләргә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.
Москва, Кремль.
13 февраль, 1940 ел.

Латвиянең чит ил эшләре министре Мунтерс әфәнденең рече

РИГА, 13 февраль. (ТАСС). Кичә Латвиянең чит ил эшләре министре Мунтерс әфәнде халыкара хәл турында доклад ясады. Мунтерс болай диде:

„Үзара ярдәмләшү турында Советлар Союзы белән пакт төзелүгә 4 ай үтте. Аның тормышка ничек ашырылуына кайбер йомгаклар ясау өчен бу срок җитәрлек. Ике илнең дә пактны тормышка ашыруга дуслык һәм үзара ышаныч рухында якын килгәнлекләрен күрсәтеп үтәргә кирәк.

Без 5 нче октябрь пакты турында чит ил матбугаты аңлатуларын игтибар белән күзәттек һәм мин аларның безне (һәр хәлдә беренче вакытта булса да) канәгатьләндермәгәнлекләрен әйтә алам. Соңгы вакытта чит ил матбугатының бәя бирүе инде икенче төс алды, чөнки Латвия—Совет мөнасәбәтләренең нинди атмосферада киңәюе һәр кемгә күренә. Чит ил газеталарында вакыт-вакыт кабатланып тора торган ике төп раслауга кагылып, мин „советлаштыру“ кайда соң дип сорыйсым килә. Ә бит безне анардан кисәткәннәр иде. Латвиядә Советлар Союзы безнең эчке эшләребезгә ни дәрәҗәдә булса да катнаша дип әйтерлек гомумән нинди булса да кеше бармы икән? Чит ил матбугатында Латвияне „бәйсезлеген югалткан протекторат“ дип атыйлар. Фактлар мондый раслауларның да нигезсез икәнлеген күрсәтәләр.

Советлар Союзы белән хәзерге мөнасәбәтләр тулысынча канәгатьләнерлек дип әйтергә нигез бар. Бу уңайлы хәлләр бары тик вакытлы характерда гына дип һәм безгә СССР ның эчке һәм тышкы политик басымы белән кайчан булса да хисаплашырга туры килер дип раслаучы кешеләр бар. Мондый сүзләрнең нинди фикерләргә нигезләнүе — шул кешеләрнең сере. Һәр хәлдә хөкүмәтнең тәҗрибәсе бу сүзләрне акламый“.

Аннары министр немец милләтендәге гражданнарны репатриацияләү (илләренә кайтару) турында 30 нчы октябрьдә төзелгән Латвия—Германия договорына да тулысынча тукталды.

Сугышның беренче айлары безнең күзебезне ачтылар. Бу соңгы айлар безнең күзебезне киләчәк вакытка да ачалар. Без үзебездән: бу бөек бәрелеш ныклы тынычлыкның җиңүе белән тәмам булырмы дип сорыйбыз. Бүген җавап юк әле, ләкин ул иртәме яки соңмы бирелер. Мин шулай ук бу сугышта һәм көчләрнең һәм идеяләрнең аның тарафыннан китереп чыгарылган бәрелешендә халкыбызның һәм дәүләтебезнең позициясе нинди дип сорарга тиешмен. Ул төп принципка—безнең бәйсез милли яшәвебезне тәэмин итүгә кайтып кала. Безнең барлык тышкы политик адымнарыбыз бөтен буын буена шушы максатка гына юнәлдерелеп килде. Соңгы елларда, Европаның язмышына җитәкчелек итүче бөек державалар арасындагы мөнасәбәтләрнең яшрен төстә, ләкин һаман көчәеп бара торган кискенләшүен күреп, халыкара куркынычсызлык системасының көчсезләнүен күреп, халыкара бергәләп эш итү бинасының акрынлап җимерелә баруын күреп, без нейтралитет позициясенә торган саен ныграк борыла барабыз. Үзебезгә чит булган эш өчен кораллы көрәштә катнашудан безнең дәүләтне бары тик шушы политика гына чикләп калачакны без яхшы аңлыйбыз.

Бүген без, сугыш алласының арбасы безне читләтеп үтте дип әйтә алабыз. Безнең хәзерге хәлебез үзебезнең югарыда аңлатылган бәйсез милли яшәвебезне тәэмин итү политикасыннан гыйбарәт булган төп принципны яклап килә алганлыгыбызны һәм яклап килә белгәнлегебезне генә исбат итә. Ирекле латыш халкы үзенең хәзерге позициясеннән бер нинди шартларда да чигенмәс. Без халыкның бердәмлегендәге тиңдәшсез көчтән, шулай ук үзебезнең сәламәт милли һәм иҗтимагый структурабыздан дәрт алабыз. Латвиянең милли тормышы үз культурасын булдыру юлыннан ышаныч белән бара. Бездә мәгариф һәм сәнгать үзләренең милли рухларының бәйсезлегенә бер кем дә шик тотмый торган халыкларныкы белән бер дәрәҗәдә үк тора“.

ПАРТИЯНЕҢ ҖИТӘКЧЕ ОРГАННАРЫН САЙЛАУЛАРНЫ XVIII НЧЕ СЪЕЗД КАРАРЛАРЫНЫҢ ҮТӘЛҮЕН ТИКШЕРҮ БИЛГЕСЕ АСТЫНДА ҮТКӘРИК!

ЗУР ҖАВАПЛЫ ЭШ

Казан энергокомбинат партоешмасында 61 член һәм 30 кандидат бар. Кандидатларның күбесе 1939 нчы елны кабул ителгән иптәшләр.

Партиягә яңа кабул ителгән бу иптәшләрне большевистик тәрбияләү башлангыч партоешманың игътибар үзәгендә торырга тиеш иде. Фактта исә анда эш алай тормый. Оешмадагы коммунистлар арасында „ВКП(б) тарихының кыскача курсы" н өйрәнү эшенең канәгатьләнерлек тормавы моны бигрәк тә ачык күрсәтә. Кандидатлардан 18 кеше партия тарихын үзлекләреннән өйрәнергә теләкләрен белдергән, ләкин аларның күбесе „Кыскача курс" ның берничә бүлеген генә өйрәнгәннәр әле. ВКП(б) тарихын урта звено буенча өйрәнүче Беркутов һәм Гарталова иптәшләр „Кыскача курс" ның II нче бүлеген генә өйрәнә башлаганнар. Партия тарихын өйрәнү өстендә системалы рәвештә шөгыльләнүче коммунистларның тәҗрибәләрен уртаклашу һәм теоретик беседалар үткәрү мәсьәләсе дә онытылган. ВКП(б) тарихын түгәрәкләрдә өйрәнергә язылучылар белән занятиеләр оештырылмаган. Партбюро бу мәсьәләне үзенең утырышына да куеп тикшермәгән.

Партоешмада яшь коммунистларны партия эшенә өйрәтү ныклы юлга салынмаган. Партбюро аерым иптәшләргә партпоручениеләр бирү белән генә чикләнә. Поручениеләрнең үтәлешен системалы рәвештә тикшерми. Кандидатка, бигрәк тә җитәкче эшкә күтәрелгән иптәшкә, теге яки бу мәсьәләдә практик булышлык һич тә җитәрлек түгел. Кандидатлардан 5 кешегә партпоручение дә бирелмәгән әле.

Җирле Советларга сайлаулар вакытында кандидатлардан 12 кеше агитатор булып һәм 15 кеше сайлау комиссияләренең членнары булып актив эш алып барганнар. Ә сайлаулардан соң партоешма бу активлыкны ныгытмаган. Күп кенә агитаторлар хәзер үзләренең мактаулы эшләреннән читләшкәннәр. Алар белән бер семинар да үткәрелгәне юк.

Партбюро яшь коммунистлар белән ел буена берничә җыелыш үткәрү белән генә чикләнеп калган, аларның көндәлек эше һәм сораулары белән конкрет рәвештә кызыксынмаган. Мәсәлән, ВКП(б) кандидаты иптәш Гарталованы үткән ел яз профсоюзның культработниклар хәзерләү курсына җибәрәләр. Курстан кайткач, аны клуб мөдире итеп куялар. Ул анда 6 ай эшли. Ләкин аңа клубта эшләү, бигрәк тә актив туплау бик кыен була. Шундый моментта иптәш Гарталовага партоешма тарафыннан да конкрет булышлык күрсәтелми. Шуннан соң ул бу эштән китәргә мәҗбүр була.

Бу фактлар партоешмада кандидатлар арасында эшләүнең үз агымына куелганлыгы турында сөйлиләр.

Отчет-сайлау җыелышында коммунистлар партоешманың эшендәге менә бу һәм башка шундый җидди кимчелекләрне тагын да тулырак ачарга тиешләр. Партоешмада кандидатларны большевистик тәрбияләү һәм аларны партия эшенә өйрәтү буенча яңа составка конкрет наказлар бирелергә тиеш.

У. Ахметов.

ЦЕХ ПАРТОЕШМАЛАРЫНА ҖИТӘКЧЕЛЕКНЕ ЯХШЫРТЫЙК

Житен комбинатының эрләү фабрикасы партоешмасы коммунистларның идея-политик дәрәҗәләрен үстерү һәм производствода аларның авангардлык рольләрен күтәрү мәсьәләре буенча күп кенә карарлар кабул иткән. Ләкин ул карарларны үтәү эшен оештыру ягы начар тора. Партбюро секретаре иптәш Жезлова барсын да үзе генә эшләргә омтыла, партбюро членнарын һәм коммунист активистларны бу эшкә ныклап тупламый. Оешманың эше 4 ай буена плансыз алып барылган.

Коммунистларның идея-политик дәрәҗәләрен күтәрү эше буенча секретарь аерым беседалар үткәрү белән чикләнгән, партия тарихын үзлекләреннән өйрәнүчеләргә конкрет ярдәм оештырылмаган. Партия тарихы һәм агымдагы политик мәсьәләләр буенча оештырылган түгәрәкләрнең занятиеләре күптәннән инде үткәрелгәне юк.

Фабрикада политик масса эшләре кирәгенчә җәелдерелмәгән. Эшчеләр арасында социалистик ярышны һәм стахановчылык хәрәкәтен җәелдерү эше белән партбюро йомшак шөгыльләнә. Фабрикадагы коммунистларның авангардлык рольләрен күтәрү эше бигрәк тә начар тора. Турыдан-туры производствода эшләүче 17 коммунистның 9 ы гына айлык планны үтәгән.

Партоешмада отчет-сайлауларга хәзерлек эше башланмаган да әле. Партбюро секретаре иптәш Жезлова: „Иртәгә башлармын әле" дип бу эшкә бик җиңел карый.

Бу фабрикада партоешманың эше шундый хәлдә булуы өчен җаваплылык комбинат партбюросы өстенә дә төшә. Комбинат партбюросы фабрикалардагы партоешмаларга конкрет һәм системалы рәвештә җитәкчелек итми әле. Цех партоешмаларының эшен яхшырту мәсьәләсенә отчет-сайлау җыелышында зур игътибар бирелергә тиеш.

Шаһиев.

Наркомат янындагы партоешма

ВКП(б) ның яңа уставында партиянең наркоматлардагы оешмаларының бурычлары бик ачык билгеләнгән. Уставта болай диелә: „Партиянең наркоматлардагы оешмалары, совет учреждениеләре эшенең махсус шартлары аркасында контроль функцияләре белән файдалана алмаганлыктан, учреждениенең эшендәге кимчелекләр турында сигнал бирергә, наркоматның һәм аның аерым работникларының эшендәге җитешсезлекләрне күрсәтергә һәм үзләренең материалларын һәм фикерләрен ВКП(б) ҮК на һәм наркомат җитәкчеләренә җибәрергә тиешләр".

Ләкин Татарстан АССР Наркомпросы янындагы башлангыч партоешма, наркомның приказларын тикшерү, халык мәгарифенең бишьеллык планын, 3—4 нче классларда укытуны яңа алфавитка күчерү һәм башка шуның кебек, үзенең функциясенә кермәгән эшләр белән шөгыльләнгән. Ә, шул ук вакытта Наркомпроста эшләүчеләр арасында хезмәт дисциплинасын ныгыту, волокитаны бетерү мәсьәләләре белән, хезмәт ияләренең жалобаларына, хатларына бюрократик караш фактларын бетерү мәсьәләләре белән оешма тиешенчә шөгыльләнмәгән.

ВКП(б) ның Өлкә Комитеты бюросы узган елның 10 нчы ноябрендә Наркомпрос партоешмасының эшендәге бу зур җитешсезлекләрне ачты һәм үзенең карарында аларны төзәтү юлларын күрсәтте.

Наркомпрос партоешмасы ВКП(б) Өлкә Комитетының бу карарын тормышка ашыру буенча соңгы вакытта кайбер практик чаралар үткәргән. Мәсәлән, мәктәп идарәсенә килгән жалобаларны карауның торышы, зурлар мәктәпләре идарәсе белән метод кабинеты арасында булган мөнәсәбәт, балалар йортлары бүлеге эшләренең торышы тикшерелгән. Шулай ук наркоматта эшләрне рационаллаштыру турында мәсьәлә каралган.

Ләкин болар башлангыч эшләр генә. Наркомпрос аппаратында эшләрне партиянең XVIII нче съезды куйган таләпләр югарылыгына күтәрү өчен партоешмага бик күп эшләргә кирәк әле. Чөнки, наркоматта эшләүчеләр арасында хезмәт дисциплинасының торышы йомшак, шулай ук наркоматка килгән жалобаларга, хатларга караш мәсьәләсендә булсын, волокитаны бетерү, үтәлешне тикшерү мәсьәләсендә булсын Наркомпрос аппаратында җидди кимчелекләр әле дә яшәп килә. Мәсәлән, мәктәпләр идарәсе (начальнигы иптәш Лаврова) Кукмарадагы татар урта мәктәбендә эшләрнең торышы начар булуы турындагы хәбәрне һәм Ширәмәт районыннан Сиделкина дигән кешедән килгән хатны шул районнарның РОНО ларына җибәрү белән тынычланган. Ә алар буенча урында нинди чаралар күрелүе турында бөтенләй кайгыртмаган.

Наркоматның кайбер җитәкче работниклары тарафыннан сигналларга игътибарсыз караш һәм тәнкыйтьне кысу фактлары да бар. Мәсәлән, бүлекләр арасында төзелгән ярыш договорын карап чыгу өчен нарком иптәш Контюков аларны үзенә ала. Ләкин аларны 45 көн үзендә тотып та, карамыйча бүлекләргә кире кайтара. Наркомпрос янында чыга торган стена газетасы социалистик ярышка болай игътибарсыз каравы өчен иптәш Контюковны тәнкыйть итә. Ләкин иптәш Контюков бу һәм моңа охшаган башка сигналларга җавап бирүне дә кирәк дип тапмый.

Наркомпроста большевистик тәнкыйтьнең кирәгенчә җәелмәгәнлеген күрсәткән бу фактлардан партоешма тиешле практик нәтиҗә ясарга, аппарат эшен яхшыртуга барлык работникларны ныграк тупларга тиеш.

Ә. Ишкәев.

Казан тимер юлы станциясенең хәрбиләштерелгән охранасы работниклары (сулдан уңга) П. Г. Кузмичев, М. О. Винскуров, С. И. Гордеев һәм В. Н. Сергеев иптәшләр „ВКП(б) тарихының кыскача курсы" н өйрәнү вактында.

И. Галиев фотосы.

КОММУНИСТ-ҖИТӘКЧЕ

Пөхтә генә киенгән, киң маңгайлы, какчарак кына яшь кеше минем кабинетка керде.

— Производство начальнигы сез буласызмы?

— Әйе,—дидем мин. Дусларча кул бирешеп күрешкәннән соң, ул урындыкка килеп утырды.

— Мин заводның яңа сайланган партбюро секретаре Вахитов булам, таныш булыйк,—дип сүз башлады ул.

Беренче танышлык билгесе итеп ул миннән производстводагы коммунистларның ничек эшләүләре турында белергә теләгәнлеген әйтте.

Яңа таныш белән ничә сәгать сөйләшеп утырганбыздыр, хәтерләмим, шактый вакыт үтте, цехтагы һәрбер коммунист турында белгәннәремнең барын да тезеп чыктым.

— Бу иптәшләрне үз яныма чакырып алып сөйләшермен, аларны производство алдынгылары итү өчен бөтен көч белән тырышырбыз. Минем янга кергәләгез. Коммунистлар эштә сезгә кирәгенчә булышлык итмәсәләр, миңа әйтегез, ярдәм итәрмен,—диде дә иптәш Вахитов, дусларча исәнләшеп, кабинеттан чыгып китте.

Без аның белән әнә шулай танышып, дуслашып киттек.

Иптәш Вахитов 3 нче номерлы фанер заводындагы коммунистларның һәм партиясез большевикларның барсы белән дә менә шулай танышты.

Мин партиясез, ләкин һәрбер читен мәсьәләләр булганда партбюро секретарена керү миндә гадәт булып китте.

Партбюро җитәкчесенең һәр нәрсә белән кызыксынуын, бөтен эшне тикшерүен, һәр кемгә ярдәм итүен завод һәм цех работниклары һәр вакыт сизәләр.

Чимал мәсьәләсе өзелү куркынычы астында тора иде. Яшь директор, ярдәм сорап иптәш Вахитовка бармый, кемгә барсын!

Коммунистларны, стахановчыларны һәм белгечләрне җыйдык, киңәшләштек. Эшнең җаваплы участкыларына коммунистлар куелды, чималны саклау һәм тоту турында конкрет чаралар билгеләнде.

Иптәш Вахитов коммунистларга заводта уйлап табу эшенең торышын тикшерүне тапшырган икән. Күп җитешсезлекләр ачылган. Технорукның бу эшне күзәтмәве, аңа җитәкчелек итмәве, уйлап табучыларның җыелышы үткәрелмәве билгеле булды.

Партбюро секретаре заводның техноругын күреп:

— Сез уйлап табучыларны оныткансыз, ә бит алар—зур көч, алар—стахановчыларның иң алдынгы һәм фикер иясе өлеше, заводыбызның күз карасы,—диде.

Иптәш Вахитов үзе белән сөйләшүчене дәртләндерде, бу участкыда җитешсезлекләрнең төзәтеләчәгенә аңарда ышаныч тудырды.

Технорук кабинеттан чыккач, маңгай тирен сөртә-сөртә:

— Менә нинди кеше, үзе сүкмәде дә, беседа гына ясады ясавын, ләкин тирләмәс җиреңнән тирләрсең,—диде.

Уйлап табучылар белән үткәрелгән киңәшмә технорук кыска гына доклад ясады. Алар, кемнең нинди начальник булуына карамастан, каты тәнкыйть белән чыктылар. Технорук тагын бер кат „тиргә батты".

Аннары, алдынгыларны бүләкләү, ахырда күңел ачулар булды.

Партбюро секретаре, уйлап табучылар турында кайгыртучанлык күрсәтүне әнә шулай башлады, бу җидди эшне онытмаска өйрәтте. Шуннан соң эш бөтенләй башкача бара башлады. Уйлап табучылар заводның иң почетлы кешеләре булып әверелделәр, алар яхшырак эшли башладылар, тәкъдимнәр дә артты.

Юка такта телү машиналарында еш була торган аварияләр заводның эшенә тоткарлык ясыйлар иде. Иптәш Вахитов, коммунист слесарьларны җыеп, алар алдына бурычны ачык куйды, аларның киңәшләрен тыңлады. Производствоның механигы, коммунист Таловтан тәкъдимнәрне үтәүнең төгәл срокларын таләп итте һәм аларның үтәлүен көн саен тикшереп торды. Ахырда аварияләрнең бөтенләй бетерелүенә иреште. Шуннан соң бу механизмнар сәгать механизмнары кебек эшли башладылар.

Үзебездә басма газета чыгару мәсьәләсен биш елдан бирле күзгатып килгән идек. Парткомның элекке секретарьлары, ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты рөхсәт бирми, дип килделәр. Ләкин бу дөрес булып чыкмады. Иптәш Вахитов ВКП(б) Өлкә Комитеты белән беренче тапкыр сөйләшүеннән соң ук газетаны чыгарырга рөхсәт бирелде.

Мондый мисальләрне күп китерергә мөмкин. „Кечкенә" нәрсәләр дә партбюро секретареның игътибарыннан читтә калмыйлар, бу гаҗәп кешенең бар нәрсәгә дә ничек вакты җитүенә хәйран каласың! Ватаныбыз өчен чын күңелдән бирелгәнлеген ул шулай практик эштә күрсәтә һәм башкаларны да шуңа өйрәтә.

Иптәш Вахитов завод коллективы арасында гына түгел, шәһәрдәге хезмәт ияләре арасында да авторитет казана алды: аны Зеленодольский шәһәр Советына депутат итеп сайладылар. Ә шәһәр Советының беренче сессиясендә аны шәһәр Советы председателенең урынбасары итеп сайладылар.

Монда гаҗәпләнерлек бер нәрсә дә юк. Нак менә шундый яхшы оештыручылар гүзәл илебезнең дәүләт эшлеклеләре булырга тиешләр дә.

Н. В. Ильинский.

Балаларны тәрбияләү— гаять зур бурыч

Гомуми мәҗбүри уку партиябезнең тарихи XVIII нче съезды тарафыннан куелган бөек бурычлар белән турыдан-туры бәйләнгән. Сталинчыл өченче бишьеллык планда ул бөтен тулылыгы белән күрсәтелә. „Шәһәрдә гомуми урта белем бирүне тормышка ашыру, авылда һәм барлык милли республикаларда 7 еллык гомуми белем бирүне төгәлләү бурычы куелды" (В. М. Молотов).

Бу—эшче сыйныфның культура-техник белем дәрәҗәсен тагын да күтәрү дигән сүз, бу—социализмнан теземле рәвештә коммунизмга күчү өчен иң кирәкле шартларның берсе. Аңа бары тик Наркомпрос органнары эше дип кенә карап булмый. Ул,—бөтен партия, совет, комсомол оешмалары һәм барлык ата-аналар эше, бөтен халык эше. Бу бурычны уңышлы үтәү өчен бөтен ил көрәшә.

Орденлы Татарстан республикасы гомуми мәҗбүри укуны тормышка ашыруда күренекле уңышларга иреште. Урта, тулы булмаган урта мәктәпләрнең һәм башлангыч мәктәпләрнең саны елдан-ел туктаусыз үсә. Мәктәпләрдә укучы балалар саны арта бара. Совет укытучылары армиясе яшь буынны тәрбияләүче куәтле культура көче булып әверелде.

Гомуми мәҗбүри уку өлкәсендә ирешкән уңышларыбыз, һич шиксез, зур. Шулай да, без бу өлкәдә бик яхшы эшлибез дип, мактана алмыйбыз әле. Әгәр дә урыннардагы партия, комсомол һәм җәмагать оешмалары гомуми мәҗбүри уку эше белән тагын да яхшырак һәм тагын да тирәнрәк шөгыльләнсәләр, безнең уңышларыбыз да күбрәк булырлар иде.

Республикабызның күп кенә районнарында бу гаять зур политик әһәмиятле эш тиешле югарылыкка күтәрелмәгән. Кайбер районнарда уку елы башланганда күп кенә балалар укуга тартылмый калганнар һәм шуның өстенә балаларның мәктәптән төрле сылтау белән китү фактлары да бар. Чүпрәле районында шушы елның беренче январена 388 бала укуга тартылмаган һәм 626 бала укуны ташлаган. Октябрь районында 255 бала укуга тартылмаган булса, 983 бала мәктәпкә йөрүдән туктаган. Буденный районында 236 бала, Сарман районында 243 бала, Беренче Май районында 8 яштәге 73 бала, 9—11 яштәге—125 һәм 12—14 яштәге—249 бала укуга тартылмаган.

Бу районнарның мәгариф бүлекләренең җитәкчеләре һәрбер фактка „тулы сәбәп" күрсәтергә хәзер торалар. Аларның статистика отчетларында „сәбәпләр" саны күп. „Сәбәпләр" арасында: балаларның укуга теләкләре „юклыгын", кайбер ата-аналарның балаларын укытырга „теләмәүләрен", балаларның мәктәпкә баруларының оештырылмавын һәм башка шундыйларны күп очратырга мөмкин. Бу дөресме соң? Юк, дөрес түгел. Безнең бөек Ватаныбыз һәрбер баланы укыту өчен тулы мөмкинлекләр булдырды. Димәк, эш мәктәпкә һәм балаларны укытуга тулы игътибар бирүдә, шул мөмкинлекләрдән тулы файдалану өчен көрәш оештыруда.

Уку елының беренче яртысында республикабызның күп кенә мәктәпләре күренекле уңышларга ирешүләренә карамастан, кайбер мәктәпләрнең практик эшләрендә җидди кимчелекләрне очратырга туры килде. Уку елының беренче яртысын Казан шәһәренең кайбер мәктәпләре аеруча начар күрсәткечләр белән тәмамладылар.

Уку яшендәге балаларны мәктәпкә тарту белән бергә, аларның отлично һәм яхшы укуларына ирешү өчен көрәш мәктәп работникларының һәм партия, комсомол, җәмагать оешмаларының мактаулы эше. Ләкин Казан шәһәре халык мәгариф бүлеге отлично һәм яхшы уку өчен көрәш мәсьәләсе белән дә мактана алмый. Казанда уку елының беренче чиреге 69,3 процент өлгереш белән тәмам булган иде. Шәһәр халык мәгариф бүлеге һәм аның мөдире иптәш Бекшанский бу саннан үзенә тиешле нәтиҗә ясап, икенче чиректә югары өлгерешкә ирешү өчен бөтен көчне тупларга тиеш иде. Кызганычка каршы, бу эшләнмәде һәм, нәтиҗәдә, уку елының беренче яртысы 72,2 процент өлгереш белән генә тәмам була.

Казанда гүзәл эш үрнәкләре күрсәтүче мәктәпләр һәм укытучылар аз түгел. Ләкин РОНО җитәкчеләре аларның эш тәҗрибәләрен уртаклашуны, укытучыларның киң массасы арасында популярлаштыруны тиешле дәрәҗәдә оештырмыйлар. Кайбер мәктәпләрнең укытучылар коллективы арасында булган җидди кимчелекләрне үз вактында бетерү өчен җитәрлек чара күрелми. 85 нче мәктәптә булган фактлар моны тулысынча раслыйлар. Бу мәктәптә санитария кагыйдәләре сакланмый: анда тузан, пычрак, мәктәптә балаларның тәмәке тартулары гади бер нәрсә булып әверелгән. Балалар мәктәп тәртибе белән таныш түгелләр. Расписаниенең дөрес төзелмәве аркасында дәресләр еш кына өзеләләр. Тихомиров һәм Мускалева иптәшләр җитәкчелек иткән класслар уку елының беренче яртысын 33—43 процент өлгереш белән генә тәмам иттеләр. Кышкы каникулдан соң да эшнең үзгәргәне юк әле. Моның сәбәбен укытучылар коллективына җитәкчелектән эзләргә кирәк. Коллектив яхшы уңышларга ирешә алырлык укытучылардан тора. Ләкин коллектив уку елын отлично темамлауга тупланмаган. Мәктәпнең уку-укыту бүлеге мөдире Рожкова үзенең тупаслыгы, бюрократлыгы белән эшне таркаулыкка алып бара. Ул, укытучыларга укучылар алдында төрле пычраклыклар ташлаудан да баш тартмый. Укытучы иптәш Малышева мәктәптә физкультура дәресен алып бару өчен кирәкле шартлар булдыруны сорап килгәч, ул: „бездәге шартлар ошамаса, гариза язгыз да эштән китегез" дип кырт кисә. Рожкова укытучыларның инициативаларын каплап калдыра, тәнкыйтьне кыса. Бу турыда Сталин районы мәгариф бүлегенә берничә сигнал бирелә, ләкин алар ни өчендер томаланып калдырылалар.

Совет балаларын коммунистик рухта тәрбияләү эше мәктәптә һәм мәктәптән тыш алып барылырга тиеш. Партия һәм хөкүмәт мәктәптән тыш тәрбияләү эшенә гаять зур әһәмият бирәләр. Бездә укучы балаларның мәктәптән тыш вакытларын файдалы һәм культуралы итеп үткәрү өчен тулы мөмкинлекләр бар. Пионерлар һәм мәктәп балалары клубы, „Пионер" кино-театры, яшь тамашачылар театры, балалар паркы һәм башкалар балаларны бөек Ватаныбызның лаеклы кешеләре итеп тәрбияләргә чакырылган оешмалар. Бу оешмаларның эшләрен балаларның сорауларын канәгатьләндерерлек итеп оештырганда, файдалы нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин.

Балаларны тәрбияләүдә завод, фабрикаларның, учреждениеләрнең тоткан урны аеруча зур. Моннан берничә ел элек завод, фабрикалар аерым мәктәпләрне шефка алып, аларның эшләренә конкрет булышлык күрсәтәләр иде. Ләкин соңгы елларда шефлар үзләренә беркетелгән мәктәпләрне оныттылар. Ул гына да түгел, хәтта кайбер предприятие җитәкчеләре шефлык турында сүз кузгатырга да шикләнәләр. Менә бер факт. Молотов районындагы 19 нчы мәктәптән Трампарк җитәкчеләре янына килеп, үзләренә ярдәм күрсәтүне сорыйлар. Ләкин Трампарк җитәкчеләре бу эшкә аптырап калалар, һәм:

— Сез ялгыша торгансыздыр, хәзерге вакытта шефлык турында нинди сүз булуы мөмкин?—дип җавап кайтаралар.

Балаларны тәрбияләүдә һәм укытуда ата-аналарның җаваплылыгы гаять зур.

Москва шәһәренең „Серп и молот" заводының эшчеләр, хезмәткәрләр коллективы балаларны тәрбияләү буенча булган эшне тагын да яхшыртырга чакырып, Советлар Союзының барлык эшчеләренә, колхозчыларына, интеллигенциясенә мөрәҗәгать иттеләр. Алар үз өсләренә конкрет йөкләмә итеп, укучыларның отлично һәм яхшы укуларына ирешүне, аерым мәктәпләр каршында бакчалар, волейбол, баскетбол мәйданнары булдыруны, техника, хәрби эш, физкультура, художество-үзешчәнлек түгәрәкләре булдыруны һәм аларны квалификацияле кадрлар белән ныгытуны алдылар.

Орденлы республикабызның эшчеләр һәм хезмәткәрләр коллективлары да бу гүзәл башлангычны зур күтәренкелек белән каршы алырлар һәм предприятиеләргә, учреждениеләргә якын торган мәктәпләрне шефка алып, аларның эшләренә конкрет булышлык күрсәтерләр дип ышанырга кирәк.

Партиябезнең тарихи XVIII нче съездында иптәш Сталин болай диде: „Без барлык эшчеләрне һәм барлык крестьяннарне культуралы һәм белемле итәргә телибез һәм без моны вакты белән эшләрбез". Бөек юлбашчыбыз тарафыннан куелган бу бурычны якын арада үтәү—ул, партия, совет, комсомол оешмаларының һәм бөтен совет халкының мактаулы эше.

Рим Баһау.

Стахановчылык хәрәкәтенең яңа формаларын большевикларча үзләштерик!

ЭШ ТӘЖРИБӘЛӘРЕ БЕЛӘН УРТАКЛАШЫЙК

Стахановчылык хәрәкәтенең яңа формалары—күп станокларда эшләүгә күчү, берничә профессияне үзләштерү, ирләр хезмәтен хатын-кызлар хезмәте белән алмаштыру кебек мөһим чаралар Серго Орджоникидзе исемендәге заводта көннән-көн киң урын ала бара. Бу өлкәдә зур гына уңышларга ирешкән стахановчылар үзләренең эш тәҗрибәләре белән уртаклашалар.

Стахановчыларның бу гүзәл омтылышларын искә алып, заводта стахановчыларның эш тәҗрибәләрен уртаклашу буенча махсус группа оештырылды. Производство алдынгыларының уңышлы эш тәҗрибәләрен өйрәнүне, аны бөтен завод күләмендә җәелдерүне, стахановчылар мәктәпләре оештыруны, комплексы бригадалар төзүне, стахановчылык хәрәкәтенең һәр төрле яңа формаларын бөтен чаралар белән үстерүне группа үзенең төп бурычы итеп куйды.

Заводның хезмәтне оештыру бүлеге янында төзелгән бу группа, үзенең беренче адымы буларак, күптән түгел генә токарь П. Фирсов (ремонт-механика цехы) һәм фрезеровщик Кильдибеков (механика цехы) иптәшләрнең эш тәҗрибәләре белән уртаклашуны оештырды.

Стахановчы токарь иптәш Фирсов безнең заводта 1935 нче елдан бирле эшли. Ул заводның иң алдынгы рационализаторларыннан берсе. Аның тарафыннан кертелгән рационализация тәкъдимнәрен тормышка ашыру хезмәт җитештерүчәнлеген югары күтәрү белән бергә, заводка йөз меңнәрчә сум экономия ясау мөмкинлекләрен дә бирде.

Иптәш Фирсов яхшы стахановчы. Ул эштә ашыкмый. Аның һәрбер хәрәкәте нык исәпләнгән. Эш урны үрнәкле итеп оештырылган. Ул 420 минутны тулысы белән эшкә файдалана. Шуңа күрә дә иптәш Фирсов үзенең производство заданиесен һәр айда 300—400 процент итеп үти һәм аена 2.000—2.500 сум хезмәт хакы ала.

Фрезеровщик иптәш Кильдибеков та заводыбызның мактаулы кешеләреннән берсе. Ул үзенең эш урнын һәр вакыт дөрес оештыра, вакытны рациональ рәвештә файдалана. Детальне эшләүгә керешүдән элек, ул аны ничек итеп җиңелрәк һәм тизрәк эшләү юлларын белгели. Аның хезмәтне җиңеләйтә һәм тизләтә торган күп кенә яңалыклары бар. Мәсәлән, яссы детальне ясау өчен аның тарафыннан уйланган җайлылык аеруча зур әһәмияткә ия булып тора.

Иптәш Кильдибеков горизонталь фрезер станогында кайбер рационализаторлык чаралары куллану аркасында, бер детальне эшләүгә китә торган вакытны 300 минуттан 100 минутка кадәр кыскартуга ирешә. Элек бу детальне эшләү өчен токарь станогыннан файдаланылган булса, хәзер иптәш Кильдибеков методы белән бу эшне гади фрезер станогында да башкарып була.

Берьюлы берничә станокта эшләүче алдынгы стахановчыларның—рационализаторларның бай тәҗрибәләрен башкаларга күчерү буенча оештырылган махсус группа февраль аенда үзенең эшен аеруча киңәйтүне планлаштырды.

С. Кәримуллин, Г. Рафиков.

РАЦИОНАЛИЗАТОРЛАР

Серго Орджоникидзе исемендәге заводның алдынгы стахановчылары— рационализаторлар республикабызның данлыклы XX еллыгына яңа бүләкләр хәзерлиләр. Алар юбилей хөрмәтенә яңадан-яңа рационализация тәкъдимнәре кертәләр.

Менә, заводыбызның мактаулы стахановчысы иптәш Нәгыймов тәкъдимен алыйк. Аның тарафыннан кертелгән тәкъдим эш шартларын күп җиңеләйтү белән бергә, хезмәт җитештерүчәнлеген 250 процентка күтәрү мөмкинлеген бирә. Ә иптәш Сорокин клепалка эшен механикалаштыру тәкъдимен кертте. Бу тәкъдим хезмәт җитештерүчәнлеген 150 процентка күтәрә. Стахановчы иптәш Әхтәмгәрәев тәкъдимен тормышка ашыру елына 150 мең сумлык экономия ясау мөмкинлеген бирә. Рационализатор иптәш Денисов электроэнергия бирә торган яңа машина уйлап тапты. Бу машина ягулыксыз эшләячәк.

Рационализаторлар соңгы вакытларда аеруча зур активлык белән эшлиләр.

Г. Ялышев.



Серго Орджоникидзе исемендәге завод алдынгыларыннан бер төркем (сулдан уңга): мастер—электромонтер М. И. Мельников, слесарьлар группасы өйрәнчеге П. В. Кузнецова, токарьлар группасы мастеры Н. Н. Ветров, слесарь Ф. У. Чебатков, такелажчы З. Гарипов һәм слесарь П. В. Мельников иптәшләр.

А. Толокнов фотосы.

СТАХАНОВЧЫЛЫК ХӘРӘКӘТЕНДӘГЕ ЯҢАЛЫКНЫ ҮСТЕРИК

4 нче номерлы ясалма каучук заводының 8 нче цех начальнигы иптәш Усманов белән сөйләшү

4 нче номерлы ясалма каучук заводында күп станокчыларның саны артканнан-арта бара. Безнең 8 нче цехта гына да хәзер 48 кеше күп станокта эшләүгә күчтеләр. Алар хезмәт җитештерүчәнлегенең югары үрнәкләрен күрсәтәләр.

Стахановчылык хәрәкәтендәге бу яңалык бездә үткән елның октябрь аенда ук башланды. Без моңа алдан ныклы хәзерлек чаралары күрдек, шартлар тудырдык. Күп станокчыларның барсы да диярлек стахановчылар мәктәбендә укып чыктылар.

Алдан хәзерлек чаралары тәэмин ителгәннән соң, без вакуум-мешалка һәм рефайнер агрегатларында өчәр кешене күп станокларда эшләүгә күчердек. Аларның беренче тәҗрибәләрен өйрәндек. Стахановчылардан инструктор булып күтәрелгән Гәрәев һәм Волков иптәшләр аларга бик зур булышлык күрсәттеләр, үзләренең бай тәҗрибәләрен тырышлык белән уртаклаштылар.

Күп станокчыларның эшләре нәтиҗәле, алар машиналардан, эш сәгатьләреннән тулы файдалануның югары үрнәген бирәләр. Волоснов, Сөнгатуллин, Сафиуллин һәм башка иптәшләр һәр кайсы икешәр станокта эшләп, нормаларны арттырып үтиләр. Хатын-кызлар агрегатының эше аеруча характерлы. Бу агрегатта Хәсәнова, Букрева һәм Хәмәтҗанова иптәшләр өчесе элек 6 ир кеше башкара торган катлаулы процесста эшлиләр. Алар өчесе 6 кеше нормасын үтиләр.

Производство техникасын өзлексез яхшырта барабыз. Бу тармакта уйлап табучыларның хезмәте зур. Орденлы механик иптәш Гордеев станокларны сүтмичә үз урыннарында валекларга ремонт ясау юлын эзләп тапты. Элек валекларга ремонт ясау өчен станокларны бөтенләй сүтәргә мәҗбүр була идек. Ремонт өчен унар көн вакыт кирәк була иде. Хәзер без бу ремонтны бик тиз вакыт эчендә ясыйбыз.

Безнең бу методны хәзер каучук промышленностеның башка заводлары да кулланалар.

Күп станокчы иптәш Лысачов вальцы машинасына механик пычак кую буенча гаять кыйммәтле тәкъдим бирде. Производство техникасына мондый үзгәреш кертү нәтиҗәсендә, өч вальцы машинасында бер кеше эшли алачак. Иптәш Лысачов тәкъдимен якын көннәрдә тормышка үткәрү өчен практик чаралар күрәбез, тәҗрибә эшләре алып барабыз.

Күп станокчыларга булышлыкны бөтен яклап көчәйтергә кирәк. Ләкин заводның партия һәм профсоюз оешмасы аларга тиешле булышлыкны күрсәтми әле. Шушы көнгә кадәр заводта күп станокчыларның бер тапкыр да киңәшмәсе булганы юк.

Стахановчылык хәрәкәтендәге бу яңалыкны тагын да үстерү һәм киңәйтү өчен производство техникасын өзлексез яхшырта барырга, күп станокчылар мәктәбенең прогрммасын киңәйтергә, каучук промышленностеның башка заводларындагы уңышлы тәҗрибәләрдән нык файдаланырга кирәк. Менә бу чараларны тулысынча тормышка үткәргәндә күп станокчыларның эшләре тагын да тизрәк алга барачак.

ЯХШЫ БАШЛАНГЫЧ

Серго Орджоникидзе исемендәге заводның ремонт мастерское күп төрле станокларга һәм инструментларга ремонт эшләрен башкара. Ремонтчыларның бер генә төрле профессияне үзләштерүләре аркасында, станокларны ремонтлау һәм ремонттан соң аларның сыйфатын тикшерү эшләренә зур тоткарлык ясала иде.

Хәзер бездә берничә профессияне үзләштерү хәрәкәте башланды һәм ул үзенең гүзәл нәтиҗәләрен бирә. Ике-өч төрле профессияне үзләштергән кешеләр хәзер бездә күпләп санала. Ә бу исә ремонт эшләрен тизләтүгә зур этәргеч ясады.

Слесарь иптәш Васин токарьлык квалификациясен җентекләп үзләштерде. Хәзер ул слесарьлык һәм токарьлык эшләрен бер үзе башкара. Мастерскоебызның алдынгы стахановчысы иптәш Иванов сверло станогында шомарту эшенә зур яңалык кертте. Бу яңалыкны тормышка ашыру элек 78 сәгаттә эшләнә торган детальне, хәзер 14 сәгат эчендә башкару мөмкинлеген бирде.

Без, ремонтчылар коллективы, станокларны кыска срокта, отлично билгесенә ремонтлау өчен намус белән көрәшәбез.

Мастер *И. Чеховский.*

БЕЗНЕҢ ЙӨКЛӘМӘЛӘР

Мехчылар чакыруына җавап итеп, безнең цех коллективы республикабызның данлыклы XX еллыгын тагын да яхшырак эшләү белән каршыларга карар бирде. Ярты еллык планны 25 нче июньгә үтәү, хезмәт җитештерүчәнлеген 20 процентка күтәрү, моның өчен күп станокларда эшләү методын үзләштерү—безнең җаваплы һәм мактаулы бурычыбыз.

Алган йөкләмәләрне практик эш белән үтәү өчен цех коллективы большевикларча көрәшә. Мәсәлән, стахановчы иптәш Губачев яңа типтагы станокны уңышлы үзләштереп, нормасын системалы рәвештә 500—600 процент итеп үти. Мастер иптәш Чеховский группасы берничә профессия үзләштерүне киң җәелдерде. Нәтиҗәдә, группа станокларга ясала торган капиталь ремонтны ике тапкыр тизләтте. Иптәш Әхтәмовның үткән елны өйрәнчекләрдән оештырылган группасы тоташ стахановчы группа булып әверелде. Бу уңышларны ныгыта барган хәлдә, йөкләмәләребезне тулы үтәүгә ирешәчәкбез.

Ф. Андрианов.

Серго Орджоникидзе исемендәге заводның ремонт-механика цехы начальнигы.

Серго Орджоникидзе исемендәге заводның киң куллану товарлары җитештерү цехында. РӘСЕМДӘ: мастер иптәш К. М. Элькин эшкә башлау алдыннан слесарь иптәш Л. М. Бакaнинга инструктаж бирә. А. Толокнов фотосы.

ЯҢА НОРМАЛАР

Серго исемендәге завод коллективы яңа нормалар буенча эшли башлады. Хезмәт җитештерүчәнлеген югары күтәрүгә юнәлтелгән бу чара заводта зур күтәренкелек белән каршыланды. Бу мәсьәлә эшчеләрнең һәм инженер-техник работникларның гомуми җыелышларында тикшерелде. Алар яңа нормаларны бердәм рәвештә якладылар.

Стахановчы—комсомолец иптәш Корчагин коллектив фикрен чагылдырып, җыелышта болай диде:

— Производствоны механикалаштыру, яңа җиһазлар кертү, күп кенә эш процессларын үзгәртеп кору буенча соңгы вакытларда байтак эшләр башкарылды. Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүнең яңа методлары туды һәм туа. Шуңа күрә дә, моңа кадәр яшәп килгән нормалар хәзер искереп калдылар, аларны безнең стахановчыларыбыз, ударникларыбыз күп тапкыр арттырып үти башладылар. Яңа нормалар кертү бик вакытлы һәм әһәмиятле чара. Без, бай техниканы ныклап үзләштергән стахановчылар, яңа нормаларны да арттырып үтәячәкбез. Моның өчен бөтен шартлар, бөтен мөмкинлекләр тудырылган.

Казан шәһәренең мехкомбинат коллективы чакыруына безнең завод коллективы яңа нормаларны үзләштерү өчен көрәш белән җавап бирә. Ярты еллык планны орденлы республикабызның XX еллыгына үтәү йөкләмәсен алып, аны эш белән ныгытабыз.

Мәсәлән, ике фрезер станогында эшләүче Маслов, Максимова, строгаль Юсупов, шлифовщик Игнатьев иптәшләр яңа нормалар буенча эшләп, көнлек заданиеләрен 200—300 процентка, токарьлардан Бушев, Гыйлманов, Корчагин иптәшләр 150 шәр процентка җиткереп үтиләр.

Б. Камалов.

БЕРЬЮЛЫ 4—5 СТАНОКТА

Узган елны мин, техника белемемне үстерү нәтиҗәсендә, берьюлы 2—3 станокта эшләү методын яхшы үзләштерүгә ирештем. Норма үтәлешен 500—600 проценттан киметмим. Бу исә минем хезмәт хакымны да югары күтәрде.

Орденлы республикабызның гүзәл XX еллык бәйрәмен 4—5 станокта эшләү белән каршыларга карар бирдем. Шул йөкләмәмне үтәү өчен хәзер 3—4 станокта эшләүгә күчтем. Көнлек нормамны 250—300 процент итеп үтәвем алга куелган бурычны тулы үтәүгә зур ышаныч бирә.

Киләчәктә тагын да яхшырак эшләрмен, берьюлы 4—5 станокта эшләү методын большевикларча үзләштерермен.

К. Фирсов.

Серго Орджоникидзе исемендәге завод токаре.

Күп станокчылар хәрәкәтенә киң колач!

Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү турында Москва инструментальщиклары һәм Казан мехчылары мөрәҗәгатен безнең Серго Орджоникидзе исемендәге завод коллективы зур күтәренкелек белән каршы алды. Күпчелек цехларның стахановчылары, ударниклары һәм алдынгы уйлап табучылары хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү буенча үз өсләренә конкрет йөкләмәләр алдылар. Алар бу йөкләмәләрне намус белән үтиләр.

Бу гүзәл хәрәкәтне заводта беренче булып механика һәм инструменталь цехлары башлап җибәрде. Мастерскойлар, бригадалар, группалар һәм аерым эшчеләр арасында социалистик ярыш киң колач алды.

Күп станокларда эшләү тәҗрибәсен нык үзләштерү, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүдә барлык эчке мөмкинлекләрдән тулы файдалану социалистик ярыш договорларында төп йөкләмә итеп алынды. Йөкләмәләр эш белән ныгытыла.

Мәсәлән, механика цехының мастеры иптәш Асадуллин җитәкчелегендәге группаның январь ае программасын 11 көн алдан үтәве моның ачык күрсәткече. Февраль аенда бу группа тагын да яхшырак эшли. Иптәш Асадуллин группасының эш тәҗрибәсен башка бригадаларга күчерү нәтиҗәсендә, хәзер цехның барлык бригадалары да производство программаларын арттырып үтәүгә ирештеләр.

Алдынгы стахановчыларның гүзәл эш тәҗрибәләре кайбер цех җитәкчеләренең „күп станокларда эшләүгә күчү мөмкин түгел" дигән черек фикерләрен юкка чыгардылар. Мәсәлән, Баһаветтинов һәм Васичкин иптәшләр бер станокта эшләүдән өчәр станокта эшләүгә күчеп, производство программаларын 300—500 процентка җиткереп үтиләр. Иптәш Баһаветтинов строгальный станокларда эшләү буенча да яхшы күрсәткечләр бирә.

— Элек өч кеше башкарган эшне хәзер мин бер үзем өч станокта башкарам. Производство программамны 500 процентка җиткереп үтим. Һәр сменага ким дигәндә 50—60 сум хезмәт хакы алам. Бу әле башлангыч адым гына. Күп станокларда эшләү өчен бездә чикләнмәгән мөмкинлекләр бар. Бу мөмкинлекләрдән тулы файдалануга ирешеп, киләчәктә тагын да яхшырак эшләячәкмен, ди иптәш Баһаветтинов.

Слесарьлардан Гайфиев, Гаранин һәм Бусыгин иптәшләр дә хезмәтне берничә тапкыр җиңеләйтә торган яңа методлар кулланып, 7 сәгатьлек эшне 3 сәгат эчендә иркен рәвештә башкаруга ирештеләр һәм продукциянең сыйфатын күп кенә яхшырттылар. Алар хәзер бракны бөтенләйгә бетерделәр.

Стахановчы иптәш Фирсов элек бер кайрау станогында эшләгәндә күп кенә вактын бушка уздыра иде. Хәзер ул күп станокта эшләве һәм производство планын 250—300 процентка җиткереп үтәве, аена 2.400 сумга якын хезмәт хакы алуы турында шатланып сөйли. Иптәш Фирсов үзенең эш тәҗрибәләре белән киң рәвештә уртаклаша, башкаларга да стахановча эшләү методларын өйрәтә. Нәтиҗәдә, иптәш Фирсов эшләгән группа хәзер тулай стахановча эшләүче группа булуга ирешә.

Бездә хәзер тәҗрибәләр белән уртаклашу киң урын алып килә. Әле күптән түгел генә алдынгы уйлап табучы — фрезеровщик иптәш Кильдибеков цех эшчеләренә үзенең эш тәҗрибәләрен күчерү буенча күргәзмә оештырды. Ул резбалар эшләүдәге үзенең яңа методын бөтен мастерской коллективы белән уртаклашты. Бу күргәзмә эшчеләрдә гаять зур кызыксыну тудырды. Күргәзмәне караучылар иптәш Кильдибековның „ДИП—200" станогында элек 6 сәгат эшләнә торган детальнең хәзер 20 минутта эшләнүен үз күзләре белән күрделәр. Хәзер цехның күп кенә эшчеләре күргәзмәдә алган тәҗрибәләрен үзләренең практик эшләрендә кулланып, бер детальне эшләүгә китә торган вакытны 10—12 тапкырга киметүгә ирештеләр.

Завод эшчеләре арасында берничә төрле квалификацияне үзләштерүгә булган омтылыш гаять зур. Монда хатын-кызлар аеруча зур инициатива күрсәтәләр. Әле узган елның азакларында гына тимерчелек яки слесарьлык эше хатын-кызлар өчен авыр эш булып саналган булса, хәзер алар бу профессияләрдә ирләргә үрнәк булырлык күрсәткечләр бирәләр.

Мәсәлән, элек цехта курьер булып эшләгән Сабирҗанова, Калинина иптәшләр хәзер тимерчелек эшен яхшы үзләштереп, нормаларын арттырып үтиләр. Иң авыр эш участкысына бригадир итеп күтәрелгән иптәш Глебова бригадасы членнары да зур күтәренкелек белән эшлиләр. Январь ае планын бригада 11 көн элек үтәде. Бу бригада белән ярышып эшләүче иптәш Хәмидуллин бригадасы да алдынгылардан калышмый. Айлык планны 140—150 процентка җиткереп үти.

Болар әле беренче уңышлар гына. Эчке мөмкинлекләрдән тагын да киңрәк файдалану, алдынгыларның эш тәҗрибәләрен киң җәелдерү өлкәсендә производство командирларына зур бурычлар йөкләтелә. Ә профсоюз, партия һәм хуҗалык җитәкчеләре бу гүзәл башлангычка киң массаны тартуда һәр яклап булышлык күрсәтергә, большевистик җитәкчелек итәргә тиешләр.

Заводта эшнең менә бу әһәмиятле участкысы йомшак оештырылган әле. Цехта күп станокларда эшләү өчен тулы шартлар тудырылмавы, производство планының бригадаларга, мастерскойларга үз вактында җиткерелмәве, инструментларның җитешмәве турында стахановчыларның һәм ударникларның еш кына зарланулары бик урынлы.

Менә бер факт. Заводның механиклары стахановчыларның эшендә уңай шартлар тудыру, станокларны бер-беренә якынайту эшен уңышлы башкару өчен үзара социалистик ярышны зур дәрт белән башлап җибәргәннәр иде. Бу уңышлы башлангычны киң җәелдерү турында нарком приказы да бар. Ләкин механиклар арасында башланып киткән бу ярышка заводның механика бүлеге җитәкчеләре һәм завод директоры тиешенчә булышлык итмиләр.

Завод җитәкчеләре бу кимчелекләрне якын арада бетерергә, күп станокчыларга тулы эш шартлары тудырырга һәм бу гүзәл хәрәкәткә большевистик җитәкчелек итәргә тиешләр.

Г. Миңнуллин.

„Орджоникидзечы" газетасы редакторы.

ТАССР-ның XX еллыгына хәзерлек

„СПАРТАК" КОМБИНАТЫНДА

„Спартак" комбинатының зурлар мәктәбе (мөдире иптәш А. Кошкин) Татарстан республикасының 20 еллыгын зурларны укыту эшен яхшы итеп кую белән билгеләү өчен көрәшә. Мәктәп, комбинаттагы укый-яза белмәүчеләрне һәм аз укый-яза белүчеләрне 100 проценты белән кыска срокта укуга тарту, Татарстанның 20 еллыгына 115 кешене укытып чыгару турында йөкләмә алды. Бу йөкләмәне үтәүдә культармеецлардан Бердникова һәм Кулеева иптәшләр аеруча яхшы эшлиләр. Укый-яза белмәүчеләрне һәм аз укый-яза белүчеләрне укуга тарту буенча аңлату эше алып баралар. Иптәш Бердникова 57 кеше укыта, иптәш Кулеева 9 группага җитәкчелек итә. Алимбикова, Егорова, Емельянова иптәшләр укый-яза белмәүчеләрне өйләренә барып укыталар.

***

„Спартак" комбинатының Осоавиахим оешмасы (җитәкчесе иптәш Лазарев) данлыклы Кызыл Армиянең XXII еллыгын осоавиахим эшен үрнәк рәвештә кую, призывникларны хәрби эшкә яхшы итеп өйрәтү белән каршылау өчен көрәшә.

Күптән түгел генә чаңгы походы булды. Походта 19 призывник катнашты. Призывниклар хәрби эшне зур кызыксыну белән өйрәнәләр. Алардан „Ворошиловча атучы" значогына 27 кеше, „Диңгезче" значогына 30 кеше нормалар тапшыруга хәзерләнәләр. 20 кеше пулемет өйрәнә. Кызыл Армиянең XXII еллыгы алдыннан комбинатта ату һәм граната ыргыту ярышлары булачак.

Ш. Г.

СТАХАНОВЧЫЛЫК ВАХТАЛАРЫ

Зеленодольскидә Татарстанның XX еллыгына хәзерлек уңае белән предприятиеләрдә ТАССР ның XX еллыгы исемендә стахановчылык вахталары һәм бригадалар оештырыла.

Шәһәрнең хезмәт ияләре гүзәл еллыкка күп кенә бүләкләр хәзерлиләр. Социалистик шәһәрчек һәм „Красная горка" поселкысы радиолаштырыла, 4 катлы торак йорт төзелеп бетә. Автобус хәрәкәте оештырыла.

Юбилей көннәренә ГТО ның беренче баскычы буенча 200 кеше, БГТО буенча 300 кеше, Ворошиловча ату буенча 200 кеше, пулемет буенча 15 кеше, граната ыргыту буенча 200 кеше һәм ПВХО буенча меңнән артык кеше значкист булырга хәзерләнәләр.

Предприятие һәм учреждениеләрдә комиссияләр төзелде. Алар Татарстанның XX еллыгын лаеклы итеп каршылау буенча хәзерлек эшләренә керештеләр.

ЯЗУ МАШИНАЛАРЫ ЗАВОДЫНДА

Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының данлыклы бәйрәме уңае белән Казан язу машиналары заводы чаңгы чабышы үткәрде. Чабышта эшче-хезмәткәрләрдән һәм инженер-техник работниклардан 170 кеше катнашты. 65 кеше чаңгы буенча ГТО значогына норма тапшырды.

16 нчы февральдә заводның яшьләре Хасан күле һәм Халхин-Гол районнарындагы сугышларда катнашучылар белән очрашалар. 19 нчы февральдә заводта оборона көне үткәрелә. Ул көнне барлык цехларда халыкара хәл, Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгы турында беседалар булачак, пулемет һәм винтовка частьләрен өйрәнү оештырылачак.

Өлкән лейтенант И. Е. Кузнецов (Урта Азия хәрби округының Н часте) командасындагы пограничниклар наряды Тянь-Шань тауларында. Е. Халдей фотосы (ТАСС фото-клишесе).

ЙӨЗЛӘРЧӘ ЯҢА ЗНАЧКИСТЛАР

Казан Дәүләт Медицина Институтында күп төрле оборона түгәрәкләре эшли. Бер ел эчендә генә дә бу түгәрәкләр тарафыннан 24 парашютчы, 13 пулеметчы, 45 Ворошиловчы атлы, 5 снайпер, ату буенча 10 инструктор, 12 радист, 8 мотоциклиц, 12 пистолетчы хәзерләнде. Түгәрәкләрдә хәзер дә хәрби специальность алучылар бик күп. Күптән түгел генә янадан өч түгәрәк оештырылды. „Ворошиловча атучы" значогына 339 кеше, ГТО значогына 291, ГСО значогына 2.536 һәм ПВХО значогына 1.995 кеше нормалар тапшырдылар.

Кызыл Армия еллыгына эшлекле хәзерлек бара.

С. Камал.

Крот аулау тыела

Җир астында яшәүче крот (сукыр тычкан) авыл хуҗалыгы өчен файдалы җәнлекләрдән санала. Ул бик күп хәшәрәтләрне ашап юкка чыгара. Шуның өстенә кротның тиресеннән яхшы мех хәзерләнә. Ләкин соңгы елларда Татарстанда крот бик азайды. Кротның үрчүенә уңайлы шартлар тудыру өчен, Татарстан Халык Комиссарлары Советы 1940 нчы елда Татарстан территориясендә крот аулауны тыярга карар бирде. Бу карарның үтәлүен күзәтеп тору авыл советларына, Дәүләтнең аучылык инспекциясенә һәм җәнлек хәзерләүче оешмаларга йөкләнде.

Салкыннар

13 нче февральдә СССР ның Үзәк районнарына Карский диңгездән салкын һава дулкыны килде. 14 нче февральгә каршы төндә Казанда һаваның салкынлыгы 28 градус, Әгерҗе һәм Бөгелмә районнарында 30 градус булды. Көндезен Казанда салкынлык 24 градуска кадәр кимеде.

Печура елгасы буенда һаваның салкынлыгы 40 градустан арта. СССР ның көньяк районнарында һава беркадәр җылы булып тора. Кырымда һаваның җылылыгы 5 градус, Кавказда—1—6 градус.

БЕЛДЕРҮ

ВКП (б) ның Казан Шәһәр Комитеты түбәндә фамилияләре күрсәтелгән иптәшләрнең 20 нче бүлмәгә эш сәгатьләрендә килүләрен яисә үзләренең адресларын белдерүләрен сорый:

Кузьма Семенович Романов—элек Казан шәһәре Молотов райсоветында эшләгән. Мөфахар Закир улы Закиров—элек Татнаркомземда аучылык дәүләт санитария инспекциясе начальнигы булып эшләгән. Абдрахман Сәет улы Насыйров—элек ВКП(б) ның Бауман район комитетында учетта торган. Григорий Иванович Ронжин—элек Казан Авиация институтында укыган. Федор Георгиевич Бирюков—элек Казан Дәүләт Мединституты төзелешенең начальнигы булып эшләгән. Митрофан Иванович Петров—элек Казан тимер юлы станциясендә үлчәүче булып эшләгән. Гатаулла Гали улы Шәрифуллин—элек Ленин исемендәге заводта эшләгән. Иван Сергеевич Сорожкин—элек Ленин исемендәге заводта эшләгән. Вера Федоровна Иванова—элек ВКП(б) ның Киров райкомында эшләгән. Александр Иванович Ульянов—элек 2 нче ТЭЦ та эшләгән. Александр Степанович Терентьев—элек сөт заводының 2 нче магазинында мөдир булып эшләгән. Семен Павлович Еремеев—элек Ленин исемендәге заводта эшләгән. Гыйлаҗетдин Габит улы Салихов—элек Шорный фабрикада эшләгән.

Югарыда фамилияләре күрсәтелгәннәрнең тору яисә эшләү урыннарын белүче гражданнардан ул турыда ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитетына белдерүләре сорала.

МӘҖБҮРИ РӘВЕШТӘ ЧӘЧӘК САЛУ

Татарстан Халык Комиссарлары Советы Татарстан АССР дагы балаларга һәм яшьләргә мәҗбүри рәвештә чәчәк салу турында карар кабул итте. Яңа туган барлык балаларга беренче тапкыр бер яшькә кадәр, аннары 4—5 һәм 10—11 яшьтә, шулай ук 18—20 яшьтә кабат чәчәк салынырга тиеш. Чәчәк салдыруны үткәрү балаларның ата-аналарына йөкләнә. Чәчәк салдыру турында белешмәләре булмаган балалар һәм яшьләр мәктәпләргә кабул ителмәячәкләр.

Балаларга чәчәк салу шәһәрдә поликлиникалар һәм амбулаторияләр аркылы, авыл районнарында врачлык участкылары аркылы үткәрелә.

ЯҢА БАКЧАЛАР

1940 нчы елда шәһәрне яшелләндерүгә хәзерлек бара. Булакның һәр ике ягы матур бакчага әйләндереләчәк. Анда 3 гектар мәйданга агачлар утыртылачак. Куйбышев урамында һәм Ягодный бистәсендә яңа бакчалар ясалып бетәчәк. Ершов кырында Бауман исемендәге бакчага һәм Лобачевский урамындагы бакчага реконструкция ясалачак.

Шәһәрнең хәзерге бакчаларына 5 мең төп агач утыртылачак. Бу эшләргә шәһәр бюджетыннан 316 мең сум акча җибәрелә. Шуның өстенә зур предприятиеләр үз территорияләрен яшелләндерү өчен ел саен берничә йөз мең сум акча тоталар.

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ ҺӘМ ХӘРБИ ДИҢГЕЗ ФЛОТЫНЫҢ XXII ЕЛЛЫГЫ

ПРОМКООПЕРАЦИЯ АРТЕЛЬЛӘРЕНДӘ

Татарстанның промкооперация артельләрендә Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгы хөрмәтенә социалистик ярыш киң җәелде.

„Казшвейпром" артеле членнары февраль аеның производство планын срогыннан элек—22 нче февральгә төгәлләргә йөкләмә алдылар.

„Промкооператор" артеле членнары бер ял көнендә кызыл армеецларга бүләк хәзерләргә карар бирделәр.

Данлыклы юбилей уңае белән артельләрдә беседалар башланды. Бәйрәм көннәрендә тантаналы җыелышлар үткәрелә. Үзешчән лек сәнгате түгәрәкләре спектакльләр һәм концертлар куярга хәзерләнәләр.

Алабуга районындагы „Суеркар" артеле членнарыннан 20 кеше „Ворошиловча атучы" һәм ПВХО значокларына нормалар тапшыруга хәзерләнәләр. Чистайдагы „Стройпром" артелендә „Ворошиловча атучы"лар түгәрәге оештырылды.

ЯҢА ТИР ТӨЗЕЛДЕ

Казан Авиация Техникумы бәйрәмне үзендә хәрби оборона эшләрен яхшырту белән каршылый. Техникумда быел 9 мең сумга төшерелеп зур тир төзелде. Җылы һәм якты аудиториясе булган бу тирда ату буенча студентлар тренировкалар үтәләр. Бәйрәмгә хәзерлек уңае белән оборона значокларына нормалар тапшыру эшләре массовый төс алды. Соңгы вакытта гына да 41 кеше „Ворошиловча атучы" значогына норма тапшырдылар. Бәйрәмгә кадәр тагын 150 кеше норма тапшырачак. Ворошиловча ату буенча 5, ПВХО буенча 5 инструктор хәзерләнде. Тагын алты кеше Осоавиахимның Татарстан Үзәк Советы янындагы курсларда инструкторлыкка хәзерләнәләр.

Бөек бәйрәмгә хәзерлек уңае белән күп төрле ярышлар үткәрелә. Командалар арасында республика күләмендә үткәреләчәк ату ярышларында катнашу хокукы алу өчен көрәш алып барыла.

23 нче февральдә техникумда зур кичә була. Кичәдә хәрби җитәкче иптәш Блохин докладыннан соң артистлар көче белән концерт биреләчәк.

ОБОРОНА ТҮГӘРӘКЛӘРЕ

М. Н. Вахитов исемендәге җиркомбинатның заводларында, цехларында һәм бүлекләрендә соңгы вакытта оборона эшләре шактый яхшырды. 12 урында оборона түгәрәкләре оештырылды. Бу түгәрәкләр хәзер значкистлар хәзерләү өстендә эшлиләр.

20 нче февральдән 23 нче февральгә кадәр комбинат күләмендә ату спорты ярышлары үткәрелә. Ярышларда катнашырга теләүчеләрдән бик күп заявкалар алынды.

Б. Вәлиев.

СПОРТ ИНВЕНТАРЬЛАРЫ ҺӘМ УЕНЧЫКЛАР ҖИТЕШТЕРҮ

Татарстанда спорт инвентарьлары һәм балалар өчен һәр төрле уенчыклар җитештерүне киңәйтергә зур мөмкинлекләр бар. Шуңа карамастан дәүләт һәм кооперация оешмалары шушы көнгә кадәр бу эшкә тиешенчә әһәмият бирмәделәр. Нәтиҗәдә сәүдә оешмалары мондый товарларны күбесенчә СССР ның башка өлкәләреннән китерергә мәҗбүр булдылар.

Татарстан Халык Комиссарлары Советы спорт инвентарьларын, уенчыкларны һәм культура товарларын Татарстанның үзендә җитештерүне көчәйтүне кирәкле тапты. Татметаллпромсоюз, Стройматпромсоюз артельләре һәм дәүләтнең күп кенә предприятиеләре мондый товарларны җитештерә башладылар инде. Алар быел балалар өчен 20.000 данә велосипед, 10.000 данә мәктәп сумкасы, 30.000 данә пенал, 5.000 комплект шахмат, 20.000 пар чаңгы һәм башка әйберләр эшләп чыгаралар. Стройматпромсоюз артельләре балчыктан яндырып һәр төрле матур уенчыклар җитештерүне үзләштерделәр.

КОЛХОЗГА БҮЛӘКЛӘР ТАПШЫРУ

Әлмәт районының „Нариман № 1" колхозы 1937—38 нче елларны һәр гектардан уртача 15,57 центнер уңыш алып, 1939 нчы елны Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашты.

Күргәзмә комитеты тарафыннан бу колхоз икенче дәрәҗә диплом, мотоцикл, 5000 сум акча белән бүләкләнде. Район башкарма комитеты колхозга Москвадан килгән дипломны һәм бүләкләрне тапшырды. Колхозчылар 1940 нчы елны һәр гектардан 100 әр пот иген уңышы алуга ирешергә сүз бирделәр.

Бу номерда 3 нче бит алмаш бит булып чыга. Авыл районнары өчен булган тиражда 1940 нчы елгы Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашу өчен Татарстан АССР буенча күрсәткечләр урнаштырыла.

Җаваплы редактор
һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

МЕДФАРПРОМНЫҢ 1 НЧЕ ФАРМЗАВОДЫ
профессор С. Б. Моисеев күрсәткәнчә хәзерләнгән һәм наркомздрав Гыйлми Медицина Советы тарафыннан рөхсәт ителгән
Посеребренный ПЕСОК № 56
дигән исем белән йөртелә торган дару эшләп чыгарды
Посеребренный песок № 56
һичбер төрле зарары булмаган, антисептик, бактерияләрне үтерү буенча гаять көчле дару. Көнкүрештә бу көмешле су сыйфатындагы дарудан түбәндәге максатлар өчен бик гади рәвештә файдаланыла: эчү өчен, теш тазарту, авыз һәм тамакны чайкау өчен, киптерелгән фруктыларны һәм яшелчәләрне зарарсызландыру өчен. Дәвалану максатлары буенча: шешү процесслары булганда, җәрәхәтләрне юу-тазарту, ангина булганда тамакны чайкау һәм башкалар өчен.
Куллану буенча тулы мәгълүматлар тартма эчендә.
АПТЕКАЛАРДА САТЫЛА
Тартмасы 100 грамм, 2 сум 25 тиен.
Урыннарда булмаса, мөрәҗәгать итү өчен адрес: Ленинград, Аптекарский проспект, 5. Фармзавод № 1 Медфармпрома

Татарстан АССР Совнаркомы янындагы Автотранспорт идарәсенең
ТОВАР-СКЛАД КОНТОРАСЫ
тимер юл станциясендә һәм пристаньдә клиентларның йөкләрен алу һәм озату буенча экспедицион, ә тимер юл станциясе һәм пристань складларыннан йөкләрне төяү яисә складларга бушату, шулай ук йөкләрне шәһәр складларында саклау буенча
клиентларына хезмәт күрсәтә
Югарыда күрсәтелгән эшләрнең йөкләрне күчерү белән бәйләнешле булганнарын контора үз транспорты белән үти.
Шартлары турында сөйләшү өчен түбәндәге адрес буенча килергә: Казан, Нариман урамы, 40. Телефоннар: 43—82 һәм 3—96. 280—3—1

16 нчы февраль, кич 7 сәгатьтә Казан Дәүләт университетының органик химия аудиториясендә Д. И. Менделеев исемендәге
Бөтенсоюз Химия Җәмгыяте Казан бүлегенең
УТЫРЫШЫ ЧАКЫРЫЛА
Көн тәртибе: 1. Суда эреми торган магний һәм кальций кушылмаларының барлыкка килүләрен һәм аерылуларын күзәтү тәҗрибәсе (С. И. АФОНСКИЙ). 2. СССР Фәннәр Академиясе янында аналитик химия буенча Бөтенсоюз конференциясе (А. М. ВАСИЛЬЕВ). 409—1

ЙОРТ ҖИҺАЗЛАРЫН ИРЕКЛЕ СТРАХОВАНИЕЛӘҮ БУЕНЧА
кулларында 258101 дән 258125 кә кадәр номерлы квитанцияләр булган гражданнар ул квитанцияләрне Киров районы финанс бүлегенә китерергә тиешләр.
Күрсәтелгән номерлы квитанцияләр финанс бүлегенә китерелмәсәләр, гамәлдән чыккан булып исәпләнәләр һәм ул квитанцияләр буенча страхованиеләнгән йорт җиһазлары бәла-казага очрый калсалар, Госстрах җаваплылыкны үз өстенә алмый. 272—1

КАЗМЕХКОМБИНАТНЫҢ
Н. К. Крупская исемендәге
ФЗУ МӘКТӘБЕ
мех әйберләре тегү буенча югары квалификацияле тегүчеләр хәзерләү өчен
УКУЧЫЛАР АЛА
УКУ СРОГЫ 1 ЕЛ.
Мәктәпкә 17—18 яштәге һәм 6—7 класс күләмендә белемле хатын-кызлар алыналар.
Гариза белән бергә, керүченең белеме һәм яше турында белешмәләр бирелергә тиеш.
Мәктәпкә алынганнарга, аларның академик һәм практик өлгерешләренә карап, айга 70 сумнан 130 сумга кадәр стипендия бирелә.
Күрсәтелгән документлар белән гариза җибәрү өчен адрес: Казан, Яңа бистә, Кече Ямашев урамы, 71. Телефон 44—14. 182—4—1

Казан Дәүләт Медицина институты студентларын урнаштыру өчен
БҮЛМӘЛӘР һәм почмак урыннар КИРӘК
Университет урамы, 13. Телефон 7—92. 267—2—1

19 нчы февраль, кич 7 сәгатьтә Казан Дәүләт Медицина институтының терапевтик клиника факультеты аудиториясендә Мединститут Гыйлми Советының ачык утырышы чакырыла һәм түбәндәге темаларда халык алдында
ДИССЕРТАЦИЯ ЯКЛАУ
ҮТКӘРЕЛӘ
1. Медицина фәннәре докторы дигән гыйлми дәрәҗә алу өчен врач Н. Е. Сидоров. Тема: „Бала тудыру вактында авыртусызландыру чараларыннан кайберләренең эчтән куу көченә тәэсире турында".
Рәсми оппонентлар: профессор И. Ф. Козлов, А. В. Кибяков һәм П. В. Манеиков.
2. Медицина фәннәре кандидаты дигән гыйлми дәрәҗә алу өчен врач Ф. К. Пермяков. Тема: „Җиләкнең, җимешнең һәм яшелчәләрнең витаминлы суларының аш казанындагы кайбер бизләрнең һәм ферментларның эшләренә тәэсире турында".
Рәсми оппонентлар: профессор А. В. Кибяков һәм З. И. Малкин.
Диссертация материаллары белән Фәнни Медицина Җәмгыятьләре китапханәсендә танышырга мөмкин. 275—1

14 нче трестның 4 нче Төзелеш конторасына, ТӨЗЕЛЕШ ЭШЛӘРЕ БУЕНЧА ЮГАРЫ КВАЛИФИКАЦИЯЛЕ ПРОРАБЛАР һәм ДЕСЯТНИКЛАР кирәк. Телефон: Промрайон коммутаторы, 1. 264—2—2

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
17 нче февральдә
КЫЮ КЫЗЛАР
Талон 117.
18 нче февральдә
көндез БАНКРОТ (талон 118)
кич КҮЗЛӘР (талон 119)
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

Татар Дәүләт Опера театры
Татар Дәүләт Академия театры бинасында.
15 нче февральдә (талон 78).
КАЧКЫН
Кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Телефоннар: 29—04 һәм 30—78.
Якын көннәрдә „ИРЕК" операсын куюга хәзерлек алып барыла.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 15 нче февральдә
МАСКАРАД
Талон 101.
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген Москваның Ленин орденлы Дәүләт циркы артистларының БЕРЕНЧЕ ГАСТРОЛЕ
СТРАТОС—3
Орденлы БАСТ җитәкчелегендә аэропланда үлем әлмәкләре һәм башка күп номерлар.
РСФСР ның орденлы артисты М. ЗОЛЛО гастрольләре дәвам итә.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 1 гә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.

КАЗГОРСТРОЙНЫҢ
Труба-Пич эшләре конторасы
1940 нчы елда төтен юлларын чистарту эшләре буенча барлык дәүләт оешмаларының һәм йорт управлениеләренең контора белән
ДОГОВОР ТӨЗҮЛӘРЕН СОРЫЙ
Контораның адресы: Казан, Островский урамы, 39/6. Телефон 24—89. 146—3—2

Совет кинематографиясенең XX еллыгы уңае белән,
„ЧАТКЫ" КИНО-ТЕАТРЫ
иң яхшы художестволы тавышсыз фильмнар буенча
КИНОФЕСТИВАЛЬ
ҮТКӘРӘ.
15 һәм 16 нчы февральдә „Санкт-Петербургның бетүе" (1925 нче елда чыгарылган), 17 һәм 18 нче февральдә „Кастусь Калиновский" (1927 нче елда чыгарылган), 19 һәм 20 нче февральдә „Чыңгыз Хан нәселе" (1928 нче елда чыгарылган), 21 һәм 22 нче февральдә „Иуда" (1929 нчы елда чыгарылган) исемле тавышсыз фильмнар күрсәтелә.
Сеансларда концерт оркестры уйный. 1—1

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Яңа фильм ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП
„УНИОН" 11, 1-20, 3-40, 6, 8-20, 10-30 да.	УНБЕР БАШКАЛА
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да	КОМСОМОЛЬСК
„Колхозник" 4, 6, 8 һәм 10 да.	Инженер Кочинның ялгышуы
„ЧАТКЫ" 6, 8 һәм 10 да.	Санкт-Петербургның бетүе
„ПИОНЕР" 10, 11-30, 1, 2, 3-30, 5-30, 7-10, 8-50, 10-30 да.	Көндезге һәм кичке сеансларда ПАТРИОТ Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ" 4, 6, 8, 10 да.	СОҢГЫ ТӨН
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	УКЫТУЧЫ

Казан тимер юлы хезмәте 1 нче ремонт участкысының югалаган түгәрәк печатен гамәлдән чыккан дип санарга. 265—1

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 245 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 613.